КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 30 декабрь | г.Казань | № 1132

Инвалидларны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыру тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль законның 20 статьясы нигезендә, инвалидларга хезмәт белән тәэмин итү гарантияләре бирү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Инвалидларны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт турындагы законнарның һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокук актларының үтәлешен ведомство тикшерүендә тотуны гамәлгә ашырганда эш бирүчеләрнең инвалидларны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартлары тудыруны тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә, шулай ук Татарстан Республикасында Дәүләт хезмәт инспекциясенә аны тикшерүдә тотуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 30 декабрь, 1132 нче
карары белән расланды

Инвалидларны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыру тәртибе

1. Бу Тәртип «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль законның 20 статьясы нигезендә эшләнде һәм инвалидларны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыру механизмын билгели.

2. Бу Тәртипне тормышка ашыру максатларында түбәндәге төшенчәләр һәм терминнар кулланыла:

инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары – хезмәтне оештыру буенча өстәмә чараларны (төп һәм ярдәмче җайланманы, техник һәм оештыру ягыннан җиһазландыруны, өстәмә җиһазландыруны адаптацияләүне һәм, инвалидның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, техник җайланмалар белән тәэмин итүне дә кертеп) таләп итә торган махсус эш урыннары (алга таба – махсус эш урыннары);

инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы – инвалид өчен үз эченә организмның зәгыйфьләнгән яки юкка чыккан функцияләрен торгызуга, компенсацияләүгә, инвалидның аерым эшчәнлек төрләрен башкаруга сәләтләрен торгызуга, компенсацияләүгә юнәлдерелгән медицина, һөнәри һәм башка реабилитацияләү яки абилитацияләү чараларын тормышка ашыру тәртибен һәм аның аерым төрләрен, формаларын, күләмнәрен, вакытларын алган оптималь реабилитацияләү яки абилитацияләү чаралары комплексы.

Бу Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 ел, 19 апрель, 1032-1 нче Россия Федерациясе Законында, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 ел, 24 ноябрь, ФЗ-181 нче Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрдә кулланыла.

3. Бу Тәртипнең гамәле Татарстан Республикасындагы барлык эш бирүчеләргә кагыла.

4. Эш бирүчеләр тарафыннан инвалидларны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартлары тудыру Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, инвалидлар өчен махсус эш урыннарын оештыруга карата таләпләрне билгели торган федераль законнар, санитария кагыйдәләре һәм нормалары, Татарстан Республикасы законнары, шулай ук башка норматив хокук актлары һәм бу Тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Эш бирүчеләр Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларның зәгыйфьләнгән функцияләрен һәм тормыш эшчәнлегенә чикләүләрне исәпкә алып, аларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын җиһазландыруга (аларның җайланмаларына) карата төп таләпләрне раслау турында» 2013 ел, 19 ноябрь, 685 нче Н боерыгы (алга таба – Россия Хезмәт министрлыгының 685 нче Н номерлы боерыгы) һәм Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «2.2.9.2510-09 нчы санитария кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 18 май, 30 нчы карары (алга таба – Гигиена таләпләре) нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыру буенча түбәндәгеләрне үз эченә алган чараларны гамәлгә ашыра:

инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә инвалидның (инвалидлар төркеменең) хезмәт шартларына ихтыяҗын (махсус эш урынын җиһазландыруны да кертеп) ачыклау;

хезмәтнең кирәкле шартларын, хезмәт һәм ял итүнең махсус режимнарын булдыру буенча чаралар исемлеген формалаштыру.

6. Махсус эш урыннары Россия Хезмәт министрлыгының 685 нче Н номерлы боерыгы нигезендә хезмәт функцияләренең бертиптагы бозылулары (чикләүләре) булган һәр инвалид өчен яки инвалидлар төркеме өчен эш бирүчеләр тарафыннан индивидуаль рәвештә җиһазландырыла.

7. Җайланма белән җиһазландырылган махсус эш урыны инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасына, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы таләпләренә, Гигиена тәләпләренә, шул исәптән түбәндәгеләргә туры килергә тиеш:

хезмәт иминлеген тәэмин итәргә;

сәламәтлеге начарлану яки җәрәхәт алу мөмкинлеген булдырмауга;

эшне шактый булмаган яки уртача булган физик һәм башка авырлыклар белән үтәүне тәэмин итәргә.

8. Эш бирүчеләргә, эшкә урнаштырылган инвалидлар ихтыяҗларына карата индивидуаль якын килүне исәпкә алып, инвалидлар өчен хезмәт шартларын тудыру буенча локаль норматив актлар (боерыклар) кабул итүне тәкъдим итәргә.

9. Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары булдыру яки бирү турында локаль норматив актларда эш бирүчеләргә түбәндәге мәгълүматларны күздә тотарга кирәк:

вазыйфалар исемен;

штат берәмлекләре санын;

хезмәт өчен түләү шартларын;

хезмәт һәм ял итү режимының махсус шартларын, шулай ук өйдә тулысынча яки өлешчә эшләү мөмкинлеген;

эшләүнең ташламалы нормаларын;

эш характерын;

инвалидларны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә инвалидларга хезмәт шартларын тудыруга бәйле булган башка мәгълүматларны.

10. Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары булдыру яки бирү турында кабул ителгән локаль норматив актлар хакындагы мәгълүмат (яки

аларның күчермәләре) алар кабул ителгән яки аларга үзгәрешләр кертелгән айдан соң килүче айның 15 енә кадәр эш бирүчеләр тарафыннан алар урнашу урыны буенча Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренә җибәрелә.

___